Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы

КАРАР

15 ноябрь 2021 ел № 50

Нурлат шәһәре Советының 2016 елның 18 апрелендәге «Җир салымы турында»гы 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыем турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, Россия Федераль салым хезмәтенең «Транспорт салымы һәм җир салымы буенча салым декларацияләрен тапшыру бурычын гамәлдән чыгаруга бәйле рәвештә Федераль салым хезмәтенең кайбер боерыкларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2019 елның 4 сентябрендәге ММВ-7-21/440@ номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 18 апрелендәге 25 номерлы карарына (2016 елның 26 сентябрендәге 34 номерлы, 2017 елның 2 сентябрендәге 54 номерлы, 2019 елның 18 июнендәге 114 номерлы, 2019 елның 17 декабрендәге 128 номерлы, 2020 елның 16 октябрендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), карарның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«9. Салым түләүчеләргә–оешмаларга ташламага хокук турында хәбәр итү өчен Россия Федераль салым хезмәтенең 09.07.20021 ел, №ЕД-7-21/646.@. боерыгы белән расланган форма буенча гариза бирергә кирәк дип билгеләргә».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин